ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.05.2019 Казан ш. № 53

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты каршында Иҗтимагый совет турында нигезләмә раслау турында» 2015 елның 17 апрелендәге 44 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты каршында Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында бертип нигезләмәгә үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, **боерык бирәм**:

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты каршында Иҗтимагый совет турында нигезләмә раслау турында» 2015 елның 17 апрелендәге 44 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2015 елның 1 декабрендәге 157 номерлы, 2016 елның 7 июнендәге 49 номерлы, 2017 елның 30 октябрендәге 188 номерлы, 2018 елның 10 декабрендәге 152 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты каршында Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«җәмгыятьтә коррупциячел торышка сабырсызлык формалаштыру.»;

5.12 пунктта икенче абзацны көчен югалткан дип танырга.

Рәис С.Е. Иванов